**Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитетының " җир кишәрлеген сатып алу турында Карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2022 елның 18 гыйнварындагы 14 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтүгә таләпләр турында» 2016 елның 26 мартындагы 236 номерлы карарына ярашлы рәвештә, Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитетының 18.01.2022 № 14 карары белән расланган җир кишәрлеген сатып алу турында Карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең административ регламентының 3.3.2.1 пунктының 11 абзацына, аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

"Төзелгән гарызнамәне формат-логик тикшерү орган (оешма) билгели торган таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүче гарызнамәнең электрон рәвешендәге һәр кырын тутырган вакытта, бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә гамәлгә ашырыла. Бердәм портал сорауның электрон рәвешендәге дөрес тутырылмаган кырын ачыклаганда, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында турыдан-туры сорауның электрон рәвешендәге мәгълүмати хәбәр аша хәбәр ителә».

2. Әлеге карарны Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

**Җитәкче** **А.А. Гасыймов**